ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

4 февраль, 2026 ел № 5/8

Шәһәр Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2024 елның 30 октябрендәге 37/6 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең Салым кодексының 406 статьясы 2 пункты 2.1 пунктчасы, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2024 елның 30 октябрендәге 37/6 номерлы Карарына (Шәһәр Советының 2025 елның 3 декабрендәге 3/7 Карары редакциясендә), 2 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«6) һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата 2,0 процент;

2026 елдан кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата, проект билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төгәлләнмәгән төзелеш объектларыннан тыш, 2,5 процент;».

2. Әлеге Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев